# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү
тәртибен бозган өчен администра-
тив җаваплылык турында

Әлеге Закон җәмәгать тәртибенә һәм идарә итү тәртибенә янаучы хокук бозуларга каршы көрәшне көчәйтүгә, Татарстан Республикасы гражданнарының тынычлыгын һәм иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

1 статья. Штраф рәвешендәге административ түләтүләр салынган зат бер ай эчендә аларны үтәмәсә,-

штраф рәвешендәге административ түләтүләр унбиш тәүлеккә кадәр административ кулга алу белән алмаштырыла.

2 статья. Вак хулиганлык, ягъни җәмәгать урыннарында сүгенү, гражданнарга мәсхәрәле бәйләнү, җәмәгать тәртибен һәм гражданнарның тынычлыгын бозучы башка шундый гамәлләр кылган өчен,-

өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә; аңа карата ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, хокук бозучы унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

3 статья. Урамнарда, паркларда, скверларда, барлык төр җәмәгать транспортында һәм башка җәмәгать урыннарында борынча кигезмичә һәм муенчаксыз этләр белән йөргән, шулай ук җәмәгать урыннарында аларны караучысыз калдырган өчен,-

16

бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Урамнарда, стадионнарда, скверларда, паркларда, җәмәгать транспортының һәр төрендә һәм, спиртлы эчемлекләрне билгеләнгән тәртиптә ваклап сату рөхсәт ителгән сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләреннән гайре, башка җәмәгать урыннарында спиртлы эчемлекләр эчкән яисә җәмәгать урыннарында кешелек абруен һәм җәмәгать әхлагын мәсхәрәләп, исерек килеш йөргән өчен, -

бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Административ чаралар кулланганнан соң бер ел эчендә яңадан шул гамәлләр кабатланса,-

ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Җәмәгать урыннарында спиртлы эчемлекләр эчкән яисә җәмәгать урыннарында исерек килеш йөргән өчен бер ел эчендә икедән артык административ чарага җәлеп ителгән зат әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне кабатласа,-

өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ә аңа карата ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, - хокук бозучы унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

Уналты яшькә кадәрге яшүсмерләрнең җәмәгать урыннарында исерек килеш йөрүләре, шулай ук җәмәгать урыннарында спиртлы эчемлекләр эчүләре өчен, -

аларның ата-аналарына яисә аларны алмаштыручы затларга бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Ата-аналары яисә башка затлар тарафыннан балигъ булмаганнарны исерткәнче эчергән өчен,-

биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Хокукка каршы гамәлләр кылуга юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы төркемгә балигъ булмаганнарны җәлеп иткән өчен, әгәр бу гамәлләр җинаять җәзасына тартырлык булмаса,-

ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына, ә аларга карата ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, хокук бозучы унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

7 статья. Балигъ булмаган балаларны тәрбияләү һәм укыту вазыйфаларын белә торып үтәмәгән ата-аналарга яисә аларны алмаштыручы затларга,-

ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Балигъ булмаган балалар тарафыннан берничә мәртәбә хокук бозуларга китерүче шундый ук гамәлләр өчен /әлеге Законның 4 статьясындагы дүртенче өлешендә һәм бу статьяның өченче өлешендә күрсәтелгән хокук бозулардан гайре/,-

ата-аналарына яисә аларны алмаштыручы затларга өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Ундүрт яшьтән уналты яшькә кадәрге яшүсмерләр тарафыннан вак хулиганлык яисә хулиганлык башкарылган өчен,-

ата-аналарына яисә аларны алмаштыручы затларга өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Отышлы уеннарда /карта, рулетка, "уймак" һ.б.ларда) акчага, әйберләргә һәм башка хәзинәләргә уйнаган, шулай ук спорт һәм башка ярышларда хосусый затлар тарафыннан ставкалар кабул иткән өчен,-

уен кирәк-яракларын, шулай ук уенда ставкага куелган акчаларын, әйберләрен һәм башка хәзинәләрен конфискацияләп, өч ми-

нималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән хокук бозуларның берәрсе өчен административ чаралар кулланганнан соң,бер ел дәвамында яңадан шул ук гамәлләрне кабатлаган затка,-

уен кирәк-яракларын, шулай ук уенда ставкага куелган акчаларын, әйберләрен һәм башка хәзинәләрен конфискацияләп,биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ә ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, хокук бозучы унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

Отышлы уеннар оештырган өчен,-

уен кирәк-яракларын, шулай ук уенда ставкага куелган акчаларын, әйберләрен һәм башка хәзинәләрен конфискацияләп, ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ә ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, хокук бозучы уннан унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

9 статья. Фахишәлек белән шөгыльләнгән өчен, -

биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Административ җәза чаралары кулланганнан соң бер ел дәвамында яңадан шул гамәлләрне кылган өчен,-

ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. Милиция хезмәткәренең, халык дружиначысының, шулай ук хәрби хезмәткәрнең, шул исәптән эчке эшләр органнарының эчке хезмәт хезмәткәренең җәмәгать тәртибен саклау буенча үз вазыйфаларын үтәгәндә хокук бозуларны туктату турында законлы таләпләренә белә торып каршы килгән өчен,-

биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ә ачылган эшнең торышына карап, хокук бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, хокук бозучы унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

11 статья. Шаһитның, зыян күрүченең, дәгъвачының яисә җавап бирүченең күрәләтә торып хокук саклау органнарына килүдән баш тартулары өчен,-

ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

12 статья. Җыелышлар, митинглар, урам җыеннары һәм демонстрацияләр оештыруның яисә үткәрүнең билгеләнгән тәртибен бозган өчен,-

өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына, ә аерым очракларда, ачылган эшнең торышына карап, хокук бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылганда, хокук бозучы ун тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

Административ чаралар кулланганнан соң бер ел дәвамында шул ук гамәлләр яңадан кабатланса,-

ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына, ә ачылган эшнең торышына карап, хокук бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, - хокук бозучы ун тәүлектән унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә

кулга алына.

13 статья. Үзләренә карата күзәтү билгеләнгән затлар тарафыннан административ күзәтү кагыйдәләрен бозган өчен,-

ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына, ә ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, бу чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, хокук бозучы ун тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

14 статья. Хезмәт белән төзәтү учреждениеләрендә, тикшерү изоляторларында, суд билгеләмәсе /карары/ нигезендә мәҗбүри дәвалау өчен билгеләнгән көчәйтелгән һәм катгый күзәтүле психиатрия сырхауханәләрендә, хезмәт белән дәвалау профилакторийларында тотылучы затларга бирү өчен тыелган әйберләрне тикшерүдән яшерен рәвештә биргән яисә төрле юллар белән бирергә тырышкан өчен,-

тыелган әйберләрне конфискацияләп, өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

15 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр - моңа вәкаләтле милиция хезмәткәрләре тарафыннан, ә 11 статья буенча хокук саклау органнарының башка вәкаләтле затлары тарафыннан да төзелә.

16 статья. Әлеге Законның 2,3 статьяларында, 4 статьясының 1,2,3 өлешләрендә күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр - шәһәр, район эчке эшләр органы башлыгы яисә аның урынбасары, шулай ук шәһәр, район эчке эшләр органнары системасындагы милиция бүлекчәләре башлыклары тарафыннан карала.

17 статья. Әлеге Законның 1,2 статьяларында, 4 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләрендә, 5,6,7,8,9,10,11,12,13,14 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне

район /шәһәр/ судьясы шәхсән карый.

Әлеге Закон нигезендә төзәтү эшләре һәм административ кулга алу рәвешендә административ җәза бирү бары тик район /шәһәр/ суды вәкаләтләренә генә карый.

18 статья. Хокук бозучы зат үзенә штраф рәвешендә салынган административ түләүләрне үтәмәсә, түләүләрне башкару мөмкинлеге булмау турында эчке эшләр органы дәлилле бәяләмә әзерли, әлеге бәяләмә шәһәр, район эчке эшләр органының башлыгы /аның урынбасары/ тарафыннан раслана һәм өч көн эчендә судка җибәрелә.

19 статья. Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр хокук бозылган урыннарда карала, ә әлеге Законның 4 статьясындагы беренче, икенче һәм өченче өлешләрендә күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләр хокук бозылган урыннарда яисә хокук бозучының яшәү урынында карала.

20 статья. Административ хокук бозу турындагы эш административ җаваплылыкка тартылучы зат катнашында карала. Әгәр эшне карауның урыны һәм вакыты турында үз вакытында хокук бозучыга хәбәр ителүе хакында мәгълүматлар булган һәм аңардан эшне карауны кичектерү турында дәлилле үтенеч кермәгән очракларда гына, эш аның катнашыннан башка да каралырга мөмкин. Әлеге Законның 1,2 статьяларында, 4 статьяның өченче өлешендә, 6,7,8,9,10,12,13 һәм 14 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне караганда, административ җаваплылыкка тартылучы затның катнашуы мәҗбүри. Эчке эшләр органы яисә судья чакырып та, судка килүдән баш тарткан очракта, әлеге зат эчке эшләр органы /милиция/ тарафыннан мәҗбүри китертелергә мөмкин.

21 статья. Административ хокук бозган затны административ рәвештә тоткарлау, аңа шәхси тикшерү уздыру һәм аның әйберләрен карау – милициянең шуңа вәкаләтле хезмәткәрләре, шулай ук хәр-

би хезмәткәрләр тарафыннан, шул исәптән хезмәт белән төзәтү учреждениеләре, тикшерү изоляторлары һәм хезмәт белән дәвалау профилакторийлары хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

Әлеге Законда күрсәтелгән хокукларны бозган затны административ рәвештә тоткарлау өч сәгатьтән дә артмаска тиеш.

Әлеге Законның I,2 статьяларында, 4 статьяның өченче өлешендә,6,8,9,I0,I2,I3,I4 статьяларында күрсәтелгән административ хокукларны бозган затлар судья яисә эчке эшләр органы башлыгы /башлык урынбасары/ тарафыннан эшне караганчы тоткарланырга мөмкин.

Административ тоткарлауның вакыты - хокук бозучыны беркетмә төзергә китерү мизгеленнән, ә исерек кешенең айныган вакытыннан исәпләнә.

22 статья. Судьяның административ җәза бирү турындагы карарына /билгеләмәсенә/ шикаять белдерелми.

Административ җәза бирү турындагы карарга /билгеләмәгә/ ризасызлык гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә белдерелә.

23 статья. Хокук бозучы тарафыннан штраф аңа штраф салыну турында карар бирелгән көннән башлап бер айдан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Хезмәт хакы алмаган уналты яшьтән унсигез яшькә кадәрге затларга салынган штраф ата-аналарыннан яисә аларны алмаштыручы затлардан тотыла.

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар өчен салынган штраф хокук бозучы тарафыннан Саклык банкы учреждениесенә кертелә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
I993 елның I8 мае
№ I857-XII